**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

егерменче утырыш
**КАРАРЫ**

11 июль 2022 ел **№ 132** Теләче ав.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча беркетмә һәм гавами тыңлаулар бәяләмәсе нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга һәм Россия Федерациясенең Территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланган документны билгеләргә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов